| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Кадряковского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кадрәк авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2022 Кадрәк авылы № 18-1

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
авыл җирлегенең генераль
планын әзерләүнең кирәк
булмавы турында

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге территориясендә җирлек территориясеннән гамәлдәге файдалануны үзгәртү күздә тотылмаганга, комплекслы социаль-икътисадый үсеш программасы юк, Татарстан Республикасының һәм Әгерҗе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемалары белән федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру каралмаганга, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

2023 елның 30 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең генераль планын эшләүдә кирәк булмауны танырга.

Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Әлеге карарны Интернет мәгълүмати телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе А.А.Михайлов

| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**РУКОВОДИТЕЛЬ**<br>**Исполнительного комитета**<br>**Кадряковского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кадрәк авыл җирлеге**<br>**Башкарма комитеты**<br>**ҖИТӘКЧЕСЕ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.11.2022 Кадрәк авылы № 21

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Башкарма комитетының эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре турында» 24.12.2014 елның 19 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 30 декабрендәге 197-ФЗ номерлы Хезмәт кодексы, 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, муниципаль норматив хокукый актларны законнарны хокукый анализлау һәм мониторинглау нәтиҗәләренә туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге башкарма комитетының 24.12.2014 елның 19 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге башкарма комитетының эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләренә кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Кадрәк авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе А.А.Михайлов